**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 8 октябрь № 751

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елда, Россия Федерациясе Пенсия фонды субсидиясен җәлеп итеп, Татарстан Республикасында яшәүче эшләмәүче пенсионерларны компьютер белемнәренә укытуны оештыру турында» 2015 ел, 30 июнь, 471 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 12 август, 587 нче карары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

түбәндәге эчтәлекле яңа 3 пункт өстәргә:

«3. 2015 елда Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына Россия Федерациясе Пенсия фонды биргән субсидияне социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләренең мобиль бригадалары өчен автотранспорт сатып алу һәм Татарстан Республикасында яшәүче эшләмәүче пенсионерларны компьютер белемнәренә укыту өлешендә Татарстан Республикасы халкына социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләренең матди-техник базаларын ныгытуга юнәлдерүне тәэмин итәргә.»;

3 пунктны тиешенчә 4 пункт дип санарга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 елда картлык һәм инвалидлык буенча хезмәт пенсиясен алучы булган эшләми торган пенсионерларга адреслы социаль ярдәм күрсәтү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 23 декабрь, 1023 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 ел, 1 октябрь, 708 нче карарының 3 нче пункты үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарның 2 нче пункты көче 2015 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип санарга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин